ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУЛПАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ЧУЛПАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАтТТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | Чулпан ав. | БОЕРЫК

«29» март 2022 ел | № 22

Чулпан авыл җирлегенең генераль
планына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары нигезендә «Максима» ҖЧҖ тәкъдимен карап чыкканнан соң һәм территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, мәйданчык объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Максима» ҖЧҖенең Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан Чулпан авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын Нурлат муниципаль районы акчалары исәбеннән әзерләү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.
2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә генераль планга үзгәрешләр кертү тәртибе, сроклары турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен кабул итәргә һәм карарга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Чулпан авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе — Ф.Ф. Зыятдинов